КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 декабрь г.Казань № 1551

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 август, 756 нчы карары белән расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 20 август 756 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 июнь, 558 нче; 2023 ел, 6 февраль, 107 нче; 2023 ел, 13 май, 589 нчы; 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшьләр сәясәте, иреклелек (волонтерлык), яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү һәм хәрби хезмәткә чакырылыр алдыннан аларны хәрби хезмәт үтүгә әзерләү өлкәсендәге чараларны һәм яшьләр өчен социаль юнәлештәге башка чараларны оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу белән бәйле

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында «смена» сүзеннән соң «(шул исәптән Россия Федерациясенең башка субъектлары балалары сменасы)» сүзләрен өстәргә;

9 пунктның алтынчы абзацында «җибәрү» сүзеннән соң «(кабул итү)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин